КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 сентябрь г.Казань № 845

2022 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда файдаланыла торган физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) кыйммәте нормативы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда файдаланыла торган физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) кыйммәте нормативын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә яшәүче бер кешегә 1 елга 1 076,6 сум күләмендә билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән 2022 елга Татарстан Республикасында физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны исәпкә ала торган корректировкалау (төзәтү) коэффициентларын расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда файдаланыла торган физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) кыйммәте нормативы турында» 2020 ел, 15 сентябрь, 834 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 8 сентябрь, 845 нче
карары белән расланды

2022 елга Татарстан Республикасында
физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә инфраструктура белән
тәэмин ителүдәге аермалыкларны исәпкә ала торган
корректировкалау (төзәтү) коэффициентлары

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Коэффициент күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Әгерҗе муниципаль районы | 0,93957 |
| 2. | Азнакай муниципаль районы | 1,11399 |
| 3. | Аксубай муниципаль районы | 0,90360 |
| 4. | Актаныш муниципаль районы | 1,97648 |
| 5. | Алексеевск муниципаль районы | 1,77365 |
| 6. | Әлки муниципаль районы | 1,35827 |
| 7. | Әлмәт муниципаль районы | 0,85876 |
| 8. | Апас муниципаль районы | 2,32219 |
| 9. | Арча муниципаль районы | 1,07087 |
| 10. | Әтнә муниципаль районы | 1,73661 |
| 11. | Баулы муниципаль районы | 1,66717 |
| 12. | Балтач муниципаль районы | 0,89299 |
| 13. | Бөгелмә муниципаль районы | 1,54270 |
| 14. | Буа муниципаль районы | 1,67998 |
| 15. | Югары Ослан муниципаль районы | 1,39753 |
| 16. | Биектау муниципаль районы | 0,82874 |
| 17. | Чүпрәле муниципаль районы | 1,20604 |
| 18. | Алабуга муниципаль районы | 1,80716 |
| 19. | Зәй муниципаль районы | 1,53278 |
| 20. | Зеленодольск муниципаль районы | 0,72656 |
| 21. | Кайбыч муниципаль районы | 1,33736 |
| 22. | Кама Тамагы муниципаль районы | 1,79999 |
| 23. | Кукмара муниципаль районы | 0,93279 |
| 24. | Лаеш муниципаль районы | 0,95617 |
| 25. | Лениногорск муниципаль районы | 1,21104 |
| 26. | Мамадыш муниципаль районы | 1,61626 |
| 27. | Менделеевск муниципаль районы | 1,93767 |
| 28. | Минзәлә муниципаль районы | 2,06545 |
| 29. | Мөслим муниципаль районы | 1,75325 |
| 30. | Түбән Кама муниципаль районы | 0,66435 |
| 31. | Яңа Чишмә муниципаль районы | 1,60381 |
| 32. | Нурлат муниципаль районы | 1,10100 |
| 33. | Питрәч муниципаль районы | 0,83909 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 34. | Балык Бистәсе муниципаль районы | 1,54894 |
| 35. | Саба муниципаль районы | 3,77989 |
| 36. | Сарман муниципаль районы | 2,10509 |
| 37. | Спас муниципаль районы | 1,33650 |
| 38. | Тәтеш муниципаль районы | 1,35326 |
| 39. | Тукай муниципаль районы | 0,57010 |
| 40. | Теләче муниципаль районы | 2,21776 |
| 41. | Чирмешән муниципаль районы | 2,15658 |
| 42. | Чистай муниципаль районы | 0,93914 |
| 43. | Ютазы муниципаль районы | 1,35871 |
| 44. | Казан шәһәре | 0,73200 |
| 45. | Яр Чаллы шәһәре | 0,84634 |